Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР №15**

Зур Мәшләк авылы 2024 елның 1 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручы К. Ә. Шәмсевәлиеваның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсендәге 6 өлешенең 2 пункты, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 маддәсендәге 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 46 маддәсендәге 1 өлешенең 2 пункты нигезендә, Шәмсевәлиева Кадрия Әсхәт кызының 2024 елның 30 сентябрендәге үз теләге белән вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы гаризасы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Шәмсевәлиева Кадрия Әсхәт кызының вәкаләтләрен, үз теләге белән отставкага китүе сәбәпле, 2024 елның 1 октябреннән вакытыннан алда туктатырга.

2. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 13А йорты, Югары Мәшләк авылы, Нариманов урамы, 24а йорты, Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50а йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы урынбасары В.И. Вафина